ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 85 от «01» 03 2023 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 19 апрелендәге «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 138 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Рассмотрев Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 11 февралендәге 20-09/2163 номерлы хаты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 4 февралендәге 100 нче номерлы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 3 декабрендәге «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында» 1095 нче номерлы карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 19 апрелендәге «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 138 нче карарына (алга таба- карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.3. пункт - Карар белән расланган мәктәпкәчә белем бирүнең уку-укыту программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балаларга компенсация түләүләре бирү тәртибен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Гаиләнең җан башына уртача керем компенсация алуга хокукларны билгеләгәндә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дарулар сатып алуга түләү турында» 2019 елның 3 декабрендәге № 1095 карары белән билгеләнгән кагыйдәләр буенча исәпләнә.».

1.2. - 2.3 пунктта 2 «компенсация билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән алдагы 12 айның соңгы алты аенда» сүзләрен «гариза биргән ай алдыннан булган соңгы 12

календарь айда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М.Р.Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов